**РЕШЕНИЕ**
**Азнакаевского районного Совета Республики Татарстан**

Азнакай шәһәре №227-32 «13» декабрь 2018ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2010 елның 22 июнендәге «Азнакай район Советының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе турында» 335-47 номерлы карары (22.09.2010 ел, №348-50, 15.03.2012 ел, №120-18, 12.08.2014 ел, №317-45, 22.03.2017 ел, №106-17 карарлары редакциясендә) белән расланган Азнакай район Советының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уставы нигезендә

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2010 елның 22 июнендәге 335-47 номерлы карары (2010 елның 22 сентябрендәге 348-50 номерлы, 15.03.2012 №120-18, 2014 елның 12 августындагы 317-45 номерлы, 2017 елның 22 мартындагы 106-17 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган «Азнакай район Советының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе турында» Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта "вазыйфаи зат, җаваплы" сүзләрен «вазыйфаи затлар, җаваплы затлар» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктның икенче абзацында, 7 пунктта, 8 пунктта, 9 пунктта " вазыйфаи зат» сүзен тиешле килештә «вазыйфаи затлар» сүзенә алыштырырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Совет норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза вазыйфаи затлар тарафыннан җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә һәм методикада үткәрелә.»;

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Граждан җәмгыяте институтлары һәм Россия Федерациясе гражданнары (алга таба - гражданнар) Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган тәртиптә үз акчалары исәбенә норматив хокукый актларга (норматив хокукый актлар проектларына) бәйсез коррупциягә каршы экспертиза уздыра алалар. Норматив хокукый актларга (норматив хокукый актлар проектлары) Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча экспертларны аккредитацияләү тәртибе һәм шартлары юстиция өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан билгеләнә.»;

Түбәндәге эчтәлекле 16.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«Норматив хокукый актларга (норматив хокукый актлар проектлары) Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү рөхсәт ителми:

1) хөкем ителгән граңданнар;

2) коррупциячел хокук бозулар кылган өчен ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү (вазыйфасыннан азат итү) рәвешендәге түләтүләр куллану турында белешмәләр ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән затлар реестрына кертелгән;

3) әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән органнар һәм оешмаларда эшчәнлекне гамәлгә ашыручы гражданнар;

4) халыкара һәм чит ил оешмалары тарафыннан;

5) чит ил агенты функцияләрен башкаручы коммерцияле булмаган оешмалар.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru

.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин